КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.11.2025 Казан шәһәре № 598-П

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында урнашкан «Сиктерме I авыллыгы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясенең чикләрен һәм аннан файдалануның аерым режимын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

әлеге боерыкның 1 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында урнашкан «Сиктерме I авыллыгы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләрен (бастырып чыгарылырга тиеш түгел);

әлеге боерыкның 2 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында урнашкан «Сиктерме I авыллыгы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән махсус файдалану режимын.

2. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә әлеге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис И.Н.Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 2025 елның
05 ноябрендәге 598-П номерлы
боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында урнашкан
«Сиктерме I авыллыгы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас
объекты территориясенең чикләре һәм аннан
**файдалануның махсус режимы**

Чикләрендә археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль законда (алга таба – 73-ФЗ номерлы федераль закон) билгеләнгән тәртиптә 73-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясында билгеләнгән археологик кыр эшләрен, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен һәм ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның аннан файдалана алуын тәэмин итү шарты белән башка эшләрне уздыру мөмкинлеген күздә тота.

Чикләрендә археологик мирас объекты урнашкан су объектыннан яисә аның өлешеннән файдалануның махсус режимы ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектка керүен һәм археологик кыр эшләрен 73-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тәртиптә уздыруын тәэмин итү шарты белән Россия Федерациясе Су кодексында билгеләнгән эшләрне башкару мөмкинлеген күздә тота.

**1. Түбәндәгеләр рөхсәт ителә:**

мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы биргән рөхсәт (ачык кәгазь) нигезендә археологик мирас объектын өйрәнү эшләрен, археологик әйберләрне эзләү һәм алу максатын күздә тоткан эшләрне дә кертеп, үткәрү;

73-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән эзләнү, проект, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен уздыру, мондый эшләрне башкару проектларында яки археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектларында, яки уздырыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен үткәрү планында археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән мәҗбүри бүлекләрне гамәлгә ашыру шарты белән, ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан файдалану һәм башка эшләр;

законнар нигезендә гражданнарның археологик мирас объектына үтеп керүен оештыру.

**2. Түбәндәгеләр тыела:**

73-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән эзләнү, проект, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен уздыру, мондый эшләрне

башкару проектларында яки археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектларында, яки уздырыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен үткәрү планында археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән мәҗбүри бүлекләрне гамәлгә ашырмыйча, ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан файдалану һәм башка эшләрне уздыру.